**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1217**
**10.03.2022**

Башкарма комитетның 2021 елның 19 августындагы 5526 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе һава киңлегеннән файдалануның федераль кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы куркынычсызлык режимы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый аклар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 19 августындагы 5526 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 27 декабрендәге 8482 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибенә, түбәндәге эчтәлектә 9.1 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«9.1. 50 метрдан артык биеклектә, шулай ук салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә җир яки су өслегенә һава юлы полосаларының проекциясе чикләрендә салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, фейерверк оештыручыга «Россия Федерациясендә һава хәрәкәтен оештыру буенча дәүләт

корпорациясе» ФДУП «Татаэронавигация» филиалының Яр Чаллы һава хәрәкәтен оештыру үзәгендә рөхсәт алырга кирәк.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов